Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе “Азнакай шәһәре 4 нче лицее”

# Җиңелмәс, тоттырмас коррупция

**“Коррупциягә “Юк” дибез!” республика бәйгесенә**
**Номинация: “Актив граждалык позициясе өчен”**

Язма авторы:
Саниева Элиза Айрат кызы, 7 нче Б сыйныф укучысы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе “Азнакай шәһәре 4 нче лицее”
Җитәкчесе:
Рафикова Эльвира Алмарис кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе “Азнакай шәһәре 4 нче лицее”

Азнакай, 2022

Хакимиятне акчага сатып алучылар аннан табыш алырга иялəшəлəр.

Аристотель

Быелның беренче яртысында ришвəтчелек Россия икътисадына 350 миллион сумлык зыян салган. Ə бу 12 мең коррупцион җинаять дигəн сүз. Илнең генераль прокуратурасы карамагындагы тикшерү комитеты шундый нəтиҗəгə килгəн. Бəйсез белгечлəр исə бу саннар белəн килешми. Алар фикеренчə, еллык ришвəт базары 300 миллиард доллардан да ким түгел.

Килешмəссең дə, кем əлеге көндə ничə сум ришвəт алганын фаш итсен ди. “Мин шундый күлəмдə акча алдым”, – дигəн кешене урамда яки башка җирдə очратканыгыз бармы? Булмас та! Хокук саклаучылар күзенə чалынган очраклар ничə меңнең берсе генə бит ул.

Түгəрəк күмəч турындагы əкиятне һəрберебез яхшы белə. “Əбидəн дə качтым, бабайдан да качтым, синнəн дə качам”, – дип мактана төп герой. Тамырлары бик тирəннəн булган коррупция дə бездəн, кешелəрдəн, ничəмə гасырлар көлə, һич тə тоттырмый. Аның белəн белгəнебезчə, Ленин да, Сталин да көрəшеп караган. Шундый глобаль Октябрь революциясен оештыру, Бөек Ватан сугышында фашистларны тар-мар итү күпкə җиңелрəк булган, күрəсең. Коррупция яшəде, булды, бар һəм җиңелергə, бирелергə җыенмый да, киресенчə, тамырларын тагы да ныграк кына җəя бара шикелле. Ул барлык дөньяда, бөтен җир шары буйлап атлый. Һəр илнең үз көрəш ысуллары. Бездə дə нинди генə алымнар кулланылмый, чаралар уздырылмый, тик тамырны төптəн өзеп ата алмыйбыз. Əкияттə аждаһаның бер башын өзеп аткач аның урынына берничə баш үсеп чыга бит, коррупция белəн көрəш тə шуңа охшаш.

Коррупция икътисадыбызның барлык тармакларына үтеп керде, дəвалап булмый торган куркыныч чиргə əверелде. Сəбəп нəрсəдə соң? Нигə бу мəсьəлəдə алга китə алмыйбыз, бер урында гына таптанабыз? Ə чүп, күпме генə тырышсак та кузгалмый, үз урынында кала бирə. Көрəш чаралары нəтиҗəле түгелме, аларны булдымы – булды, уздымы – узды өчен генə оештырабызмы, законнарыбыз кирəгенчə каты түгелме, яки тиешенчə үтəлмилəрме? Бəлки безгə яңа законнар кирəктер, бəлки безгə аерым затларга акча керү чыганагы булган нəрсəлəрне легальлəштереп, əлеге акчалар ташкынын илебез икътисадын үстерүгə

юнәлтергәдер!? Мәсәлән, хәрби билетларны сатып алуны. Солдат шинелен кияргә теләмәүчеләрдән кергән акча армиядә тиешле шартлар тудырырга җибәрелер иде.

Бездә бүген коррупция яки ришвәтчелектә гаепләп, никтер, кулга алсалар да ниндидер вуз укытучысын яки хокук сакчысын кулга алалар. Ә йөзләрчә меңнәр алып утырган түрәләр кала бирә. Аларны хәтта күрмәмешкә салышалар шикелле. Күпләр калын акча букчасын кочаклап утырып калалар. Аларны бары тик эш урыннарыннан гына бушаталар яки шартлы рәвештә ирегеннән мәхрүм итәләр. Ә гади кеше эләгеп карасын әле!.. Берничә елга төрмәгә керәчәгеңне көт тә тор.

Узган атнада республикабызның Апас районында басудан машина арбасына төяп кукуруз урлаган бер иргә карата җинаять эше ачылу турындагы хәбәрне укыган идем. Әлеге хәбәр астында берәү: “Миллионнар урласагыз, район башлыгы итеп куярлар иде!” дигән язу калдырган. Ирексездән, елмаеп куйдым. Элек тә бер уч бодай урлаган кешеләрне дистә елдан артык вакытка төрмәгә утырттканнар. Ә арба белән ташыганы шелтә белән генә калган...

Ришвәт төшенчәсе һәм ришвәтчелек тормышыбызга шулкадәр тирән үтеп керде ки, ул инде кайбер кешеләр өчен хәзер гадәти хәл. Чөнки бу хакта уку йортлары, сырхауханә һәм башка урыннарда ачыктан-ачык курыкмый сөйли башладылар. Акча түләмәсәң, танышларың булмаса, сырхауханәдә дә урын табылмаячак. Бер туганыбыз ярты ел эчендә башкала хастаханәләрендә бик күп тапкырлар дәваланып кайтты. Китәр вакыты җитсә, иң беренче эш итеп, күчтәнәч күтәреп барып, урын белешеп кайта торган иде. Ансыз берәү дә кабул итмәсен яхшы белә. Хәтта урын булган очракта да. Кызык та, кызганыч та... Барлык табибларны да бер калыпка салып карарга ярамый, әлбәттә. Араларында миһербанлылык хисләрен югалтмаганнар күбрәк.

Соңгы вакытта коррупциягә каршы көрәш илкүләм игътибар үзәгендә. Моны без Россия Президенты Владимир Путин чыгышларында да, кабул ителгән законнарда да күрәбез.

Әмма коррупция, ришвәтчелек бүген сөлек кебек җәмгыятебезгә нык ябышкан. Үзебез дә теге яки бу проблемаңны ансат кына хәл итү өчен акча төртү, бүләк бирү гадәти хәлгә әверелгән, аны законга сыешлы гамәл кебек кабул итәбез. Нәрсә соң

ул коррупция? Азнакайның Яшьләр үзәге әлеге сорау белән шәһәребез халкы арасында сораштыру үткәргән иде.

Җавап бирүчеләрнең 36 проценты аны – ришвәт алу, 30 проценты – шәхси макстларда эш урыныннан файдалану, 20 проценты – җаваплы кешеләрнең вазифаларын намуссыз башкаруы, 14 проценты бюджет акчасын урлау дип исәпли.

Шуны белә торып та, коррупциягә юл куючылар җитәрлек. «Сезнең акча төрткәнегез яки бүләк биргәнегез бармы?» – дигән сорауга сораштырылучыларның 48 проценты уңай җавап кайтарган.

«Узган ел проблемаларыгызны формаль булмаган юл белән хәл итүгә күпме акча тоттыгыз?» – дигән сорауга да җаваплар кызыклы. Сораштыруда катнашучыларның 38%ы – 5000 сумга кадәр; 26%ы – 100 сумга кадәр; 18%ы – 100-1000 сум, 12%ы – 100000 сумнан артыграк, 4%ы – 100000 сумга кадәр, 2% ы – 10000 сумга кадәр дигән.

Ә иң кызыгы шунда, ришвәт биреп тә, бары 28 проценты гына мәсьәләләрен уңай хәл итә алган.

Шулай шул, ашыгабыз, чабабыз, дөнья куабыз. Һәркайда чиратсыз үтүче кешеләргә җен ачуыбыз килә. Үзебез җиңел юл эзлибез, үзебез бар нәрсә акчага, танышлыкка корылган дип ачуланырга яратабыз.

Ә бит алучыдан бигрәк бирүче гаепле. Бирә-бирә үзебез бозып бетерәбез түгелме?